Хатыйп Миңнегулов

# «Казан утлары» һәм татар халкының әдәби-мәдәни мирасы*

Журнал-мәҗмугаларның иҗат көчләрен туплауда һәм үстерүдә, әдәбиятны алга җибәрүдә һәм пропагандалауда, гавамны тәрбияләүдә һәм оештыруда нинди мөһим урын тотуы дөнья мәдәни тормышында күптәннән расланган хакыйкать. Ә инде милли хокуклары бик нык кысылган, үз мөстәкыйль мәмләкәтләре булмаган халыклар өчен аларның роле бермә-бер арта. Мисалга 1908 елның 10 гыйнварыннан 1917 елның ахырына кадәр Оренбургта Ризаэддин Фәхреддин мөхәррирлегендә, Рәмиевләр ярдәмендә чыгып килгән (барлыгы — 240 сан) атаклы «Шура» журналын гына алып карыйк. Андагы байлык, фикер-мәгълүмат исең-акылыңны китәрерлек! Ул чын мәгънәсендә халыкның киңәш-табыш мәйданы, парламенты, дәүләте кебек. Бүгенге «Казан утлары» үзенең рәсми тарихын 1922 елда дөньяга килгән «Безнең юл» журналыннан башлый. Әмма чынлыкта аның рухи нигезләре «Шура»га барып тоташа. Аларның һәр икесен дә дәүләти фикерләү, киң колачлылык, халыкка, туган телгә, әдәбиятка хезмәт итү сыйфатлары берләштерә.

Мәгълүм ки, совет җирлегендә миллилек, дин-иманлылык хупланмады. Шул сәбәпле татарның төп журналына да, чорга, ил сәясәтенә мөнәсәбәттә, аерым тайпылышлар ясарга, вакыты белән кызылланып китәргә дә туры килде. Шунысы мөһим: мондый кыен елларда аңа миллилек, татарлык мәсьәләсендә Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектә чыгарган «Милли юл»лары, «Милли байрак»лары ярдәмгә килде. Бу өч басманың берлеге XX йөз башына хас милли казанышларны, традицияләрне сакларга, аларны яңа

---

* “Казан утлары” журналы һәм милли иәдәният” темасына багышланган төбәкара фәнни-гамәли конференциядә (Казан, 18.05.2012) сөйләнгән доклда (кыскартып бирелә).

шартларда теге яки бу дәрәҗәдә үстерергә мөмкинлек бирде. Әмма, нинди генә кыенлыкларга да карамастан, исемен алыштыра-алыштыра булса да, бу журнал төп кыйбласына тугры калды, татар яшәешенең гасырлык елъязмасы, милли-мәдәни тормышыбызның бер мәркәзе, мөнбәре вазыйфасын үтәп килде. Соңгы дәвер татар әдәби хәрәкәте, күпчелек әдипләребезнең иҗаты «Казан утлары» («Совет әдәбияты»...) белән аерылгысыз бәйләнешле. Бу журнал, аның тарихы, рухи тормышыбыздагы урыны хакында инде күп фикерләр әйтелгән (Без фәкыйрегезнең дә бу мәҗмуга турында язмалары бар). Ул үзенең озын-озак юлы, нәтиҗәле эшчәнлеге белән мондый игътибарга лаек та.

Милләт яшәешен тәэмин итүдә хәтер дәвамчанлыгы, ягъни буыннар арасындагы эчке бәйләнеш, рухи байлыкларның ата-анадан балага тапшырыла килүе үз кавемеңнең тарихын үткән юлын белү гаять зур роль уйный. Журнал үзенең бөтен яшәеш дәверендә бу хакыйкатькә тугрылык саклый. Аның сәхифәләрендә үткәнебезнең әдәби, сәнгати, тарихи, гыйльми-рухани яд5кярләре даими басылып тора. Урта гасыр сүз сәнгатенең күпчелек истәлекләре соңгы дәвер укучыларына, иң беренче чиратта, шушы мәҗмуга аша таныш. Болар арасында Йосыф Баласагунлы, Әхмәд Ясәви, Кол Гали, Котб, Сәйф Сараи, Өмми Кәмал, Колшәриф, Мәүла Колый, Габди, Габдессәлам, Утыз Имәни һәм башкаларның исемнәре, әсәрләре бар. Нәкый Исәнбәт тарафыннан, мәсәлән, журналның 1940 елгы 4 нче санында Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы укучыларга җиткерелде. Атаклы «Идегәй» дастанының шушы мөхтәрәм зат төзегән тексты да тәүге мәртәбә нәкъ менә мәҗмуга сәхифәләрендә нәшер ителде («Совет әдәбияты». — 1940. — 10—11 нче саннар).

Журнал Борынгы һәм Урта гасыр сүз сәнгате белән генә түгел, аннан соңгы әдәбият белән дә дустанә сохбәт-диалогта торды. Г. Кандалый шигырьләре, мәсәлән, мәҗмуга «Безнең юл», «Яңалиф» исемнәрен йөрткән вакытта ук анда басыла башлый. Журнал Г. Тукай, М. Гафури, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим һәм башка күренекле шагыйрьләрнең әсәрләрен дә

укучыларга җиткерә килде. Шушындый ук ихтирами караш чәчмә, драма әсәрләренә мөнәсәбәттә дә күзәтелә.

Шәхес культы фаш ителгәннән соң, аеруча Хрущевның «җепшеклек елларында» мәҗмуга элеккеге мирасның күп төрле язма истәлекләрен, шул исәптән классик әдипләребезнең әсәрләрен дә бастырып чыгарды.

Мәгълүм булганча, узган гасырның ахырларында, илдәге үзгәртеп корuларга нисбәтән, рухи мирас белән кызыксыну бигрәк тә көчәеп китте. Моңа кадәр билгесезлектә калган яисә рәсми хакимият тарафыннан тыелган күп кенә язмалар журнал сәхифәләрендә дөнья күрде. Боларның үзәгендә, әлбәттә, Гаяз Исхакый мирасы иде. Аның атаклы «Көз» повесте (1992. — №2), күпләгән публицистик, әдәби-тәнкыйди язмалары белән укучылар нәкъ менә «Казан утлары» битләрендә очрашты. Бөек әдипнең үләренә өч ай кала Финляндиядә гомер кичерүче Халидә Вафага адресланган васыять хаты бар. Мөһаҗир татарлар арасында киң таралган бу язманы бездә телгә алырга да ярамаган. Аны хәтта кайбер зыялыларыбыз, куркып, КГБ органнарына да илтеп тапшыра. «Казан утлары» Г. Исхакыйның васыять хатын кыюлык, фидакарьлек күрсәтеп, Советлар Берлеге чорында ук бастырып чыгарды (1991. — №5. — 160—169 битләр).

Журнал, әдәби мирас белән генә чикләнмичә, үткән чорларның тарихи, иҗтимагый-сәяси, фәлсәфи, дини эчтәлектәге ядкярләрен укучыларга җиткерү юнәлешендә дә эзлекле һәм нәтиҗәле эш алып бара. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның 1927 елда дөнья күргән «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән хезмәте бар. Шул чор өчен генә түгел, бүгенге милли яшәешебез өчен дә актуаль булган бу язманы кабат бастырып (1992. — №3) журнал бик тә саваплы гамәл кыллы.

«Казан утлары» әдәби, мәдәни, тарихи мирасны яктырткан аналитик язмаларны еш бастырып килә. Болар арасында бигрәк тә М. Гайнуллин, Х. Госман, Ә. Нәҗип, Г. Таһирҗанов, М. Госманов һәм башкаларның хезмәтләре игътибарга лаек.

Журнал, — иң беренче чиратта, милли мәҗмуга, татар басмасы. Әмма ул, гәрчә системалы рәвештә булмаса да, башка халыкларның мирасына да, дөнья классикасына да билгеле бер урын биреп бара. Аның битләрендә Пушкин һәм Мопассан, Нәваи һәм Физули, Мостай Кәрим һәм Рәсүл Гамзатов әсәрләренә дә тап буласың.

Һәрвакыт диярлек рухи мираска игътибарлы булган бу журнал бер гасырлап яшәү дәверендә үзе дә биниһая зур мирасны туплаган чыганакка әйләнде. Аның аркылы без татарның тарихын да, рухи хәзинәләрен дә, халыкара багланышларын да, шатлык-кайгыларын, югалту-табышларын да шактый тулы итеп күз алдына китерә алабыз. Шунысы мөһим: журналның меңенче саны чыгу уңае белән төрле елларда мәҗмугада басылган аерым материалларны туплап «Сүнмәс утлар балкышы» исеме астында зур күләмле җыентык та нәшер ителгән иде (2006. —708 б.). Безнең аңа «Мең китаптан бер китап» исеме астында язылган рецензиядә (Мәдәни җомга. — 2.03.2007) мондый юллар бар: «Бу басма мәҗмуганың гына түгел, ә гомумән татар тормышының, милли яшәешнең бер белешмәсе, чыганагы, энциклопедиясе, хрестоматиясе кебек тә».

Куелган тема белән турыдан-туры бәйләнмәсә дә, бик мөһим бер оештыру мәсьәләсе хакында фикер әйтәсем килә. Билгеле ки, рухи мирас, тел, мәгариф, әдәбият, сәнгать, матбугат, гуманитар фәннәр һәм социаль мөнәсәбәтләр бердәм дәүләти сәясәтнең үзара тыгыз багланышлы мөһим буыннары. Бу хакта заманында Г. Ибраһимов та искәрткән иде. Аның 1918 елның 24 августында «Чулпан» гәҗитендә басылган бер мәкаләсендә мондый юллар бар: «Мәктәп, матбугат, мәгариф, мәдәният — болар һәммәсе сәясәт белән гадәттән тыш бәйләнганнар...» Аларны «сәясәттән аерып карау — бу бер балалык, бу һичкайда юк һәм була алмый» (Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр. Сигез томда. 7 нче том. — К., 1984. —17 б.).

Бу хакыйкатьне истә тотып, совет чорындагы партия һәм хөкүмәт органнары мәдәният, мәгариф, матбугат кебек тармакларда эшне оештыру, алардагы эшчәнлекне үзара координацияләү белән ныклап һәм эзлекле

шөгыльләнделәр. (Хәтта кирәгеннән арттырып җибәрүләр дә булды). Хакимияттә бу тармаклар системасы өчен җаваплы махсус җитәкчеләр бар иде. Мөхтәрәм Мансур  Хәсәновның, Татарстан хөкүмәте рәисе урынбасары сыйфатында, мәгариф,  мәдәният, фән, матбугат кебек тармакларның үзара килештерелгән эшчәнлекләрен тәэмин итүдә озак еллар һәм нәтиҗәле хезмәт куюын өлкән буын яхшы хәтерлидер. Хәзер исә бу гаять җаваплы һәм мөһим эшләр, нигездә, Дәүләт Советының Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләнеп калды. Әйтергә кирәк, бу комиссия һәм аның җитәкчесе Разил Вәлиев үзләренә төшкән вазыйфа-бурычларны үтәүгә, аеруча милли мәгариф, мәдәният мәсьәләләрен хәл итүгә гаять җаваплы карыйлар, нәтиҗәле генә гамәлләр дә кылалар (Аеруча бөек шәхесебез Туфан Миңнуллинның фидакарьләрчә эшчәнлеген билгеләп үтәргә кирәк).  Әмма бит бу финанс чыганакларына, хакимият көчләренә ия булган орган түгел, ә парламент комиссиясе. Хөкүмәт составында турыдан-туры мәдәният (әдәбият, сәнгать...), мәгариф, фән, матбугат кебек тармаклар белән гомуми җитәкчелек итүче, аларның эшчәнлекләрен координацияләүче Мансур Хәсәнов кебек киң карашлы, энергияле, милли җанлы, тырыш вице-премьерның булуы зарури.

16.05.12.